МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 15.03.2020 № 112

г. Казань

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт кәгазен бирү һәм яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтнамә дубликатын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерам:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 24 декабрендәге 646 номерлы, 2020 елның 10 мартындагы 81 номерлы, 2020 елның 6 августындагы 921 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт кәгазен бирү һәм яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтнамә дубликатын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Ф.М. Ханифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгы 2021 елның
15 мартындагы 112 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт кәгазен бирү һәм яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү, рөхсәтнамә дубликатын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 нче бүлекнең 2.14 пунктында:

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә башкарыла:

а) кондиционер системасы;

б) янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;

в) Татарстан Республикасы телекоммуникацияләренең интеграцияләнгән дәүләт системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск.

г) документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;

д) мәгълүмати стендлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объекттан (алга таба - объект) файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә, ул законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә:

а) объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз кереп йөрү өчен шартлар;

б) объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, керү һәм чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып;

в) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясенең тотрыклы бозылуы булган инвалидларны озата бару һәм объектта аларга ярдәм күрсәтү;

г) инвалидларның объектка һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып тиешенчә урнаштыру;

д) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельефлы-ноктали шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

е) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы «Эт-үткәргечне махсус укытуны раслый торган документ төрен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы

боерыгы белән расланган рәвештә, аны махсус укытуны раслаучы һәм аны бирү тәртибендә бирелүче документ булганда этүткәргеч этне объектларга кертүне;

ж) хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләр тарафыннан алар хезмәт күрсәтүләргә башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.»;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы;

880 номерлы ТР МК карары;

3 бүлекнең 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт дубликатын бирү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү 3.4.1 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән кәгазьдә яки почта аша (заказлы почта аша тапшыру турында уведомление белән), рөхсәт кәгазе югалган яки аның бозылуына (рөхсәт кушымтасы белән) бәйле рәвештә рөхсәт дубликатын бирү турында гаризаны, мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның күчермәсен кушып, бүлеккә яки район пункты белгеченә җибәрә.

3.5.3. Рөхсәтнамә дубликатын бирү турында гариза кабул итү, теркәү, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документлардан баш тарту өчен нигез булмаганда, әлеге Регламентның 3.3.5 пунктында каралган процедуралар үткәрелә.

3.5.4. Ведомствоара сораулар формалаштыру һәм аларны җибәрү.

Ведомствоара оешмаларга запрослар җибәрү һәм алардан җавап алу әлеге Регламентның 3.3.5, 3.3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү.

Бүлек белгече:

рөхсәт дубликатын бирү турында боерык проектын әзерли;

әзерләнгән документлар проектын министрга (затка, аларга вәкаләтле вәкилгә) кул кую өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга (затка, аларга вәкаләтле вәкилгә) кул куюга юнәлдерелгән документлар проектлары.

3.5.6. Министр (аларга вәкаләтле зат) рөхсәт дубликатын бирү турында боерыкка кул куя. Кул куелган боерык бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура имзага документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган документлар.

3.5.7. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә;

«дубликат» һәм «рөхсәт оригиналы дөрес түгел дип таныла» тамгалары язылган рөхсәт дубликатын әзерли.

Район пункты аша рөхсәт дубликатын бирү турында гариза кергән очракта, бүлек белгече район пункты белгеченә рөхсәт дубликатын бирү турында боерык җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.5.8. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече гариза бирүчегә рөхсәт дубликатын, гариза бирүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документның оригиналын күрсәткәндә, рөхсәт кәгазенең дубликатын алу турында бирелгән журналда имза белән бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган Процедура гариза бирүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт дубликаты бирелгән.

3.5.9. Бирелгән рөхсәтләрнең статусын үзгәртү һәм Реестрын яңарту әлеге Регламентның 3.3.14 һәм 3.3.15 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

административ регламентка кушымта итеп (белешмә өчен) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазифасы, ФИАТ.ис | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсе | 264-76-62 | Aydar.Kashapov@tatar.ru». |